УДК 811.512.145

***А.Җ. Хөсәинова***

# БУРЯТИЯ ТАТАРЛАРЫНЫҢ СӨЙЛӘМ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена исследованию языковых особенностей татар, проживающих на территории Республики Бурятия, которые являются носителями переселенческих говоров. На основе анализа фонетических и лексических характеристик автор выявляет устойчивые черты, унаследованные от материнских говоров среднего (минзелинский, мамадышский, лаишевский и др.) и частично западного диалектов, а также инновации, возникшие в условиях иноязычного окружения (русский, бурятский языки). В фонетике фиксируются такие явления, как делабиализация гласных, монофтонгизация дифтонгов (*ой*/*ый* > *ы*/*и*), чередования *й*/*ж*//*дж*, выпадение смычных элементов, чередования *д*/*з* и другие позиционные изменения. Лексический пласт включает диалектизмы, связанные с бытом, родством, пищей (*кумәч, купшек, зба, стайка*), а также семантические и заимствованные единицы. Делается вывод, что изучение бурятских татар важно для понимания механизмов формирования вторичных говоров, межъязыковых контактов и сохранения диалектного разнообразия.

**Ключевые слова:** татарская диалектология, Бурятия, переселенческие говоры, говоры вторичного формирования, фонетические чередования, лексические диалектизмы, языковые контакты

The article is devoted to the study of the linguistic features of Tatars living in the territory of the Republic of Buryatia, which are migrant dialects. Based on the analysis of phonetic and lexical characteristics, the author identifies stable features inherited from the maternal dialects of the Middle (Minzelinsky, Mamadyshsky, Laishevsky, etc.) and partially Western dialects, as well as innovations that arose in a foreign-language environment (Russian, Buryat languages). Phonetics records such phenomena as the delabialization of vowels, monophthongization of diphthongs (*oh*/*y* > *y*/*i*), the replacement of y/z with j, the loss of consonant elements, alternation of n/a, d/z and other positional changes. The lexical layer includes dialectisms related to everyday life, kinship, food (*kumach, kupshek, zba, flock*), as well as semantic and borrowed units. The influence of the literary language on the younger generation is noted. It is concluded that the study of Buryat Tatars is important for understanding the mechanisms of formation of secondary dialects, interlanguage contacts and preservation of dialect diversity.

**Keywords:** Tatar dialectology, Buryatia, migrant dialects, dialects of secondary formation, phonetic alternations, lexical dialectisms, language contacts

Татар теленең сөйләшләрен өйрәнү – хәзерге диалектологиядә актуаль мәсьәләләрнең берсе. Күчмә сөйләшләр турында сүз барганда, бу аеруча мөһим. Төрле географик зоналарда таралган сөйләшләр буенча күпсанлы фактик материаллар туплануга карамастан, конкрет сөйләшләрнең диалектара мөнәсәбәт нәтиҗәләре, тирә-яктагы телләр (субстрат, адстрат, суперстрат) йогынтысында барлыкка килгән

структур үзгәрешләр, шулай ук аларның төп (ана) сөйләшләр белән чагыштырма анализы өлкәсендәге тикшеренүләр азсанлы һәм системалы түгел. Каралган тикшеренүләрнең фәнни әһәмияте югары дәрәҗәдә, чөнки аерым күчмә сөйләшләр өчен тулы структур ассимиляция процессы куркынычы яный. Шул сәбәпле җирле материалны җыю, анализлау, классификацияләү мәсьәләләрен хәл итү сорала.

Татар теленең диалектлары бик зур территорияләргә таралган. Әлеге төбәкләргә татарларның төрле чорларда, төрле күчеш юллары аша, төрле диалектологик чыгышлы халык катламнары буларак урнашуы яңа шартларда сөйләшләр үсешенә йогынты ясый. Нәтиҗәдә, яңа формалашкан сөйләшләр структурасында территорияле һәм стратификацияле күптөрлелек күзәтелә. Әмма шуның белән бергә, сөйләшләрнең барлыкка килү һәм үсеш процесслары гомуми лингвистик закончалыклар белән билгеләнә.

Беренчедән, бу – икенчел, соңрак барлыкка килгән, ягъни күчмә сөйләшләр инде формалашкан диалекталь төрләргә нигезләнә. Икенчедән, яңа урында формалашкан идиомнарның нигезе беренчел формалар нигезеннән шактый аерыла. Мондый сөйләш – я төрле диалекталь база нигезендә, я моно-диалекталь база нигезендә, ләкин изоляцияләнгән хәлдә һәм башка сөйләшләр чолганышында формалаша. Өченчедән, соңрак барлыкка килгән сөйләшләр үсеше көчле диалектара, еш кына телара контактлар шартларында бара. Дүртенчедән, күчешләр нәтиҗәсендә формалашкан территорияләр сөйләшләрнең барлыкка килүенә тәэсир итүче экстралингвистик факторларның күптөрлелеге белән аерылып тора. Бу очракта, гадәттә, әлеге факторларның сөйләшләр формалашуга тәэсире беренчел (элекке) территорияләр белән чагыштырганда көчлерәк була. Бишенчедән, икенчел сөйләшләр чагыштырмача соңрак формалаша, димәк, әдәби телнең йогынтысын да күбрәк татый [1: 22].

Әлегә соңрак күчкән территорияләрдәге сөйләшләрнең нигезле классификациясе дә, бердәм принципларга нигезләнгән тулы фәнни тасвирламасы да юк.

Бу мәкалә Бурятиядә яшәүче татарларның тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышлана. Бурятия – Россиянең көнчыгыш тарафында урнашкан, уникаль табигатьле һәм тарихи-мәдәни мираска ия төбәк. Биредә күп еллар дәвамында яшәгән татарлар җирле халыклар (бурятлар, рус телле халыклар һ. б.) белән тыгыз элемтәдә торып, телләре дә үзенчәлекле йогынты кичергән. Әлеге йогынтының телдә ничек чагылыш табуын ачыклау – актуаль фәнни мәсьәләләрнең берсе. Бүгенге көнгәчә бу территориядәге татар сөйләшләрен өйрәнгән фәнни хезмәт юк.

Мәкаләнең максаты – югарыда санап үтелгән факторларны татарларның күчмә анклав диалектларының барлыкка килүе һәм үсеше аспектында анализлау.

Татарларның Бурятия территориясенә күчеп утыру тарихында түбәндәге төп этаплар аерыла:

XIX гасыр башы – Бурятия җирләренә татарларның яңа сәүдә базарларын үзләштерү максаты белән килүе;

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы – Транссебер тимерьюлы төзелү һәм Столыпин аграр реформасын гамәлгә кую белән бәйле миграция дулкыны;

XX гасырның 1920–1930 еллар уртасы – Россиянең үзәк төбәкләрендә ачлык һәм социаль-икътисади хәл авыр булу аркасында татар халкының күчеше;

XX гасырның 1930–1970 еллары – кулакларны һәм аларның гаилә әгъзаларын сөргенгә җибәрү кампанияләре, шулай ук сәнәгать предприятиеләре (заводлар) төзелеше белән бәйле рәвештә татарларның бирегә күчерелүе;

XX гасырның 1970 еллар уртасы – 1980 еллар ахыры – Байкал-Амур магистрале (БАМ) төзелеше белән бәйле икътисади миграция процесслары [3: 194].

Бурятиягә күчеп килгән татарларның беренче дулкынын Идел-Урал төбәгеннән чыккан татар этник төркемнәре тәшкил итә.

Татарлар Бурятия Республикасының барлык районнарында диярлек таралып урнашканнар, әмма бер җирдә дә күпчелекне тәшкил итмәгәннәр. Шуңа карамастан, Бурятия территориясендә татарлар компактлы яшәгән урыннар барлыкка килгән: Заиграевский районының Иске Онохой, Татарский Ключ, Ангир, Онохой авыллары; Мухоршибирский районының Харашибирь, Мухоршибирь; Селенгинский районының Селендума бистәсе; Хоринский һәм Кижингинский районнарының Тэгдэ, Баянгол, Георгиевка, Верхние Тальцы авыллары; Баргузинский районының Ина авылы.

Бурятия Республикасы шартларында формалашкан татарларның күчмә сөйләшләре башка анклав диалектларга хас гомуми үзгәрешләрне чагылдыра. Бер яктан, бу сөйләшләрдә ана диалектларда югалып барган яки сирәк кулланылган архаик лексик һәм грамматик формалар саклана. Икенче яктан, чит телле тирәлек тәэсирендә лексика һәм фонетика байый. Нәкъ менә шушы ике каршы йөрешле процесс – архаик элементларны консервацияләү һәм чит телле инновацияләрне үзләштерү – тикшерелгән сөйләшләрнең лексик-фонетик күптөрлелеген билгели. Түбәндә Бурятия татарлары сөйләшләренең кайбер фонетик һәм лексик аермалыкларына кыскача күзәтү ясала.

Тикшерелгән ареалда, нигездә, минзәлә, мамадыш, лаеш, дөбьяз, тархан сөйләшләренә хас үзенчәлекләр саклана, шулай ук көнбатыш диалект белән уртак күренешләр дә күп. Һәм алар шактый системалы рәвештә сакланган: интерденталь [d] авазы, *ай*/*әй* дифтонгы, ике сузык арасындагы әдәби [д] авазына тел-теш [з] авазының тәңгәллеге һ. б.

## Фонетик үзенчәлекләр. Сузыклар

Сузыклар составы һәм аларның әйтелеше буенча Бурятия татарлары сөйләшләре әдәби телдән аерылмый. Аермалык [а] авазында:

сөйләш вәкилләренең күпчелеге аны лабиализацияләп әйтә [а°], ләкин информантларның бер өлешендә ачык, лабиализацияләнмәгән вариант теркәлә: *аб'и* – әби, *баз* – баз, *чак* – чак һ. б. Бу ачык вариант көнбатыш диалектында, шулай ук урта диалектның дөбьяз, пермь, касыйм, нократ сөйләшләрендә очрый [5: 21].

Сөйләшкә хас үзенчәлекләр авазларның позицион үзгәрешләренә, төрле тәңгәллекләргә кайтып кала.

Сөйләштә ирен сузыклары өлешчә яки тулысынча иренсезләштерелә. Мәсәлән:

[ө] авазын иренсезләштерү: *бетен* – бөтен, *кел* – көл, *сет* – сөт, *кез* – көз, *тен* – төн, *тетен* – төтен, *мерҗә* – морҗа, *селге* – сөлге, *йерәге* – йөрәге, *җери алмыйм* – йөри алмыйм, *йери башлады* – йөри башлады, *тен* – төн, *кен* – көн һ. б.

[о] *авазын иренсезләштерү:* өйрәнелгән сөйләшләрдә системалы характерда күзәтелә: *былыт* – болыт, *тырырга* – торырга, *ызын җул* – озын юл, *кылак* – колак, *ызын* – озын, *бырын/бырны* – борын, *кым* – ком, *кыш* – кош, *кыяш* – кояш, *йылдыз* – йолдыз, *кыйырык* – коерык, *мында* – монда, *сың* – соң, *тыкмач* – токмач, *йыклый алмыйм* – йоклый алмыйм, *пычмак* – почмак, *кыры* – коры, *йымышка* – йомычка һ. б.

Әлеге күренеш көнбатыш диалект сөйләшләренә һәм урта диалектның дөбьяз, мамадыш, камышлы, златоуст, богырыслан, каргалы, касыйм, тархан сөйләшләренә хас [5: 24].

[ы]>[а] күчеше: *аш ашайлар* – аш ашыйлар, *кыстабай* – кыстыбый, *җырлайлар ийе* – җырлыйлар иде, *сындык* – сандык, *былдак* – балдак һ. б.

[ә]>[а] күчеше: татар әдәби телендәге [ә] авазы урынына алгы рәт [а] сузыгы әйтелә: *шикар* – шикәр, *канфитлар* – кәнфитләр, *айтергә микан* – әйтергә микән һәм кире очраклар да күзәтелә, басымлы һәм басымсыз [а] сузыгы, нечкә тартыклар янәшәлегендә килгәндә, татар теленең [ә] авазы белән тәңгәлләшә: *берәз* – бераз.

Кайбер сүзләрдә, аеруча [ч] авазы янәшәсендә, [ы]/[е] > [и] *аваз күчеше күзәтелә*: *ичмә* – эчмә, *инә* – энә, *ире* – эре, *ич* – эч, *имизә* – имезә, ичке – эчке, *чир(е)гән* – чергән, һ. б. Шулай ук: җигерләү/җегерләү – эрләү, инә/энә – энә, тиге – теге.

[ә]/[и] чиратлашуы бары беренче иҗектә һәм күбесенчә [к], [ш], [ч] авазларыннан соң күзәтелә: *бәк* – бик, *кәм* – ким, *кәртә* – киртә, *биләкәй* – бәләкәй һ. б. Әлеге күренеш теге яки бу дәрәҗәдә татар теленең өч диалектында да табыла. Әмма Урал төбәгендә таралган татар сөйләшләрендә күбрәк очрый [5: 215].

Аерым сүзләрдә, киресенчә, [и]/[ә] чиратлашуы дә күзәтелә: *сике* – сәке, *җийәү* – җәйәү, *чикчәги* – чәкчәк, *пирәмәч* – пәрәмәч.

[ө]/[ү] тәңгәллеге: *мүгез* – мөгез, *төбә* – түбә (түшәм) һ. б. Шулай ук урта диалект сөйләшләрендә, мәсәлән, минзәлә сөйләшендә *бөгөн* (мишәр диалектында да шулай ук) – бүген, *шөрләү* – шүрләү; бәләбәй һәм төп урынчылыкларда *өрмәкүч* – үрмәкүч, *чөмәлә* – чүмәлә һ. б.

Чагышт.: мишәр диалектында *бөгөн* – бүген, *төгөл* – түгел, *көңөл* – күңел.

Түбәндәге сүзләрдә [у] > [ү]/[о] күчеше күзәтелә: *куз* – күз, *кукай* – күкәй, *кукрак* – күкрәк; *йулдыз* – йолдыз, *суң* – соң, *суңгы* – соңгы һ. б.

Билгеле булганча, татар һәм башкорт телләре [о]–[ө], [у]–[ү] авазларының кулланылышы буенча башка төрки телләрдән һәм шулай ук борынгы төрки телдән аерылып торалар, аларда әлеге сузыклар бер-берсе белән алыштырыла. Бу күчешләр диалектларда тәмамланмаган һәм шуңа күрә әлеге тәңгәллекләр төрле дәрәҗәдә барлык сөйләшләрдә дә очрый.

## Сузыклар төшеп калу

Казан арты сөйләшләрендәге кебек үк, бу сөйләштә дә кайбер сүзләрдә сүз башындагы сузыклар төшә: *йәңке/өйәнке* – өянке, *зата* – *озата, алды/ өйалды* – өйалды, *ләгү* – әләгү һ. б.

Сөйләштә шулай ук сузыкларның, кыскарып, бөтенләй төшеп калу очраклары күзәтелә: *ҡыл`на* – кылана, *ҡайсы/ҡайссы/ҡайсысы* – кайсысы һ. б.

Алынма сүзләрдә [р] авазы алдыннан һәм ике тартык янәшә килгән очракта [о], [э] *сузык* авазлары өстәлә: *эрәт* – рәт, *эчерек* – черек, *торба* – труба һ. б.

*өй* дифтонгы сузык авазлар алдыннан килгәндә, *ей(эй)* яисә *ий* дифтонгы белән алышына: *сейәк//сийәк* – сөйәк (сөяк), *киләп дҗыҡлата* – көйләп йоклата, *ийгә//игә кερә* – өйгә керә, *тимә//тиймә* – төймә, *кейәнтә//кийәнтә* – көйәнтә (көянтә), *кейә//кийә* – көйә (көя), *сейәл//сийәл* – сөйәл (сөял), *сейенеч//сийенеч* – сөйенеч (сөенеч), *үрәтте/үрәте* – өйрәтте һ. б.

Бу үзенчәлек [ө] ирен авазының сөйләштә иренсезләшүе белән бәйле.

*өй* дифтонгының [и]/[и](й)/[ү] булып әйтелү очраклары да бар: *сүләшкән* – сөйләшкән, *сийләшә* – сөйләшә, *кийсез* – көйсез, *тиймә* – төймә, *чий* – чөй, *кийәнтә* – көйәнтә.

*ой/ый* дифтонглары монофтонглаша: *кима* – койма, *кибат* – кыйбат, *кимак* – коймак, *кийаш* – кояш, *киз итек* – киез итек, *япмилар* – япмыйлар.

*ай/әй* дифтонглары тел алды [д], [т] тартыклары алдыннан килгәндә, [а]/[ә] авазларына күчә, *ә* тартыклар үзләре нечкәртеләләр: тел уртасы [й] авазы бөтенләй төшә: *миңгатәләр* – миңа әйтәләр, *әтәдерийе* – әйтәдер иде, *этмәдек* – әйтмәдек һ. б.

*җе*ләштерү күренеше урта диалектның төп дифференциаль билгеләреннән санала һәм Бурятия татарлары сөйләшләрендә шактый системалы рәвештә чагыла: *алҗапкыч* – алъяпкыч, *җоклaverсын* – йокласын, *җандыра* – яндыра, *җырак* – ерак, *җөрергә* – йөрергә, *җерәк* – йөрәк, *җыл* – ел, *җомырка* – йомырка, *җомшак* – йомшак, *җагырга* – ягырга, *җакын* – якын, *җарма* – ярма,

*җаңгыр җауа* – яңгыр ява, *җәмшак итеп* – йомшак итеп, *җылан* – елан.

Сөйләштәге тартык авазларның әйтелеше, нигездә, әдәби телдәгечә. Бу сөйләшкә хас фонетик үзенчәлекләр, беренчел нигез сөйләшләрдәге кебек, кайбер авазларның үзара тәңгәллекләренә һәм комбинатор үзгәрешләргә кайтып кала.

Сүз һәм иҗек ахырында [н]/[л] авазларының [н] авазына күчеше актив: *тун май* – туң май, *тыннап кына* – тыңлап кына, *тынный* – тыңлый, *аннамый* – аңламый һ. б. [ң] > [н] күчеше иялек килеше кушымчаларында һәм II зат берлек сан хикәя фигыльләрдә күзәтелә: *бирәсен* – бирәсең, *куясын* – куясың, *сорысын* – сорарсың, *аwылнын* – аwылның, *безнен* – безнең, *китәсен* – китәсең, *сугасын* – сугасың, *тордын* – тордың һ. б

Ике сузык арасындагы *н* тартыгыннан соң [ғ], [г] өстәлү күренеше дә урын алган: *күңгелле* – күңелле, *миңгатәләр* – миңа әйтәләр, *аңгар* – аңа һ. б.

Бер төркем сүзләрдә [ғ], [г] тартыкларының саңгыраулашуы бар: *тәкәрмәч* – тәгәрмәч, *калуш* – галош һ. б. Әлеге күренеш шулай ук урта диалектның мамадыш, богырыслан, турбаслы, тепекәй, әстерхан; көнбатыш диалектның темников, ләмбрә, мәләкәс, сергач һ. б. сөйләшләрендә күзәтелә [5: 245].

[к], [ғ], [х] – тирән тел арты тартыклары актив кулланылышта, бу күренеш урта диалектның төп билгесе булып тора: *қарға, қақ, қайғы, ақчи*, *уртақ* һ. б. Шуның белән беррәттән көнбатыш диалектка хас [к], [г] саклана: *туган, кайтып, кунакка.*

Палаталь [т'], [н'], [б'] тартык авазларын куллану очраклары бар: *аб'и* – әби, *б'яйрәм* – бәйрәм, *б'ергә* – бергә; *н'и* – ни, *н'ичкә* – нечкә; *т'еге* – тегe, *әт'әм* – әйтәм, *әт'и* – эти, *тәмн'е* – тәмле.

Түбәндәге сүзләрдә борынгы [п] авазы саклана: *сәдәп* – сәдәф, *керпек* – керфек, *җапрақ* – йафрак (яфрак), *тупрақ* – туфрак. Бу тәңгәллек алынмаларда да күзәтелә.

Ике сузык арасындагы [д] авазы сөйләштә [з] тартыгы белән алыштырыла: *җозороқ* – йодрык, *изән* – идән, *қазақ* – кадак, *инә қазый* – энә кадый, *бозай* – бодай. Әлеге күренеш – мамадыш сөйләшенең төп үзенчәлекләреннән берсе [5: 30].

Әдәби телдәге [з] авазына интерденталь («сакау») [d] тәңгәл килә: *бed* – без, *adep* – әзер, *куреced* – күрерсез һ. б. Әлбәттә, бу күренеш сөйләштә спорадик рәвештә күзәтелә. Ә урта диалектның минзәлә сөйләшендә исә ул – системалы күренеш [5: 217].

**Тартык авазларның төшүе**

[н] авазы сүз уртасында һәм сүз ахырында төшә: *ми әйтә* – мин әйтәм һ. б.

Күпчелек сөйләшләргә хас булганча, ике сузык арасындагы [г] тартыгы төшеп кала: *түәрәк* – түгәрәк, *җерләү* – *җегерләү* – эрләү, *тее* – тегe, *сарайды* – саргайды.

## Аерым сүзләрдә генә очрый торган тәңгәллекләр

[з]/[с]: *бес* – без; [д]/[н]: *андары* – аннары, *урмандан* – урманнан, *урдашкан* – урнашкан; [н]/[ң]: *джин* – җиң, *мен* – мең, *ан* – аң, *кин* – киң, *туна* – туңа, *тан* – таң; [с']/[ч]: *кескенә* – кечкенә, *пес'ән* – печән, *агас'* – агач, *пыс'ақ* – пычак, *умас'* – умач, *көйөнс'ә* – көйөнчә (көе); [ч]/[ш]: *шакыр* – чокыр (чынаяк), *йымышка* (йомочка).

Бурятия татарлары сөйләшендә әдәби телдәге өрелмәле [ж] яисә тел уртасы [й] авазы кушык [дж] авазы итеп әйтелә: *джидәү* – җидәү, *джыябыз* – җыябыз, *джил* – җил, *джиде* – җиде, *джимеш* – җимеш, *джанындагы* – йанындагы (янындагы), *джәйгән* – җәйгән, *джыелу* – җыелу, *җон оек* – йон оек, *джомырка* – йомырка, *джыладык* – еладык, *джуан* – юан һ. б. Сөйләү барышында шартлау элементы төрле дәрәҗәдә булырга мөмкин. Урта диалектта [дж] авазы тагын касыйм, бастан сөйләшләрендә бар. Ул көнбатыш диалектның үзенчәлекле билгеләреннән берсе булып тора [6: 10].

Сүз башында [д] шартлау элементы үзе генә дә әйтелә: *д'итен* – җитен, *д'аулық* – *җаулык* – яулык, *дьибәргәу* – җибәргәнә һ. б.

Әдәби телдән һәм урта диалектның башка сөйләшләреннән аермалы буларак, [ч] авазы да кушык [тч] булып әйтелә. Тик шартлау элементы көчле булган вариант сирәк очрый: *тчамасы* – чамасы, *тчалгы* – чалгы, *сыертчык* – сыерчык, *тчүмәлә* – чүмәлә, *тчыра* – чыра, *нитчек* – ничәк, *тчакырасың* – чакырасың, *тчия* – чия, *нитчект* – ничек, *тчиләкк* – чиләк, *япкытч* – япкыч һ. б.

## Лексик үзенчәлекләр

Бурятия территориясендәге күчмә сөйләшләрнең лексик составы кызыклы һәм үзенчәлекле. Нигездә, ул татар әдәби теленнән аерылмый. Диалект лексикасын түбәндәге тематик төркемнәр мисалында карыйк: туганлык терминнары, көнкүреш лексикасы, ризык атамалары.

Туганлык терминнары: *ана, зезни (зять), апай, абьи, әньи, әбьи, апай, әтьи, әтәй, нәнә, абай, абзай.*

«Ана» төшенчәсе *ана* / *ан'и* / *әннә* / *әни* сүзләре белән бирелә. Өйрәнелә торган сөйләшләрдән мисаллар: *коранны арапчә укыды/... юк өйрәтмим дие / син дөрес әйтмәсәң дие / бөтен синең гонаһың миңга төшәр дийе (дия иде)/ әттәнен анасы //*

«Ата» төшенчәсен *әттә/әтәй/әти* лексемалары белдерә. Мәсәлән, *әттәнен анасы.*

*Дәү әни / дәү әти* мәгънәсендә *аб'и/әби* лексемалары кулланыла. Мәсәлән, *аби өшкерәдер ийе / күкиш белән // арпа чыкты бер, ике, өч / очып китсен дип /.../ суны шыпырып / бисмилла әйтеп йабыгыз / ишекне шыпырыгы/ бисмилла диеп / мынчага эхе-эхе дип керегез //*

Көнкүреш әйберләрен билгеләү өчен кулланыла торган атамалар шулай ук кызыклы катламны тәшкил итә: *җырт* (подворье), *йялды* (двор), *түбә* (потолок), *тәрәзә капкачы* (ставни), *сындык*, *зарод* (вид

копны), *зба*, *төш* (зба төше) (двор), *ишек алды* (двор), *салкын баз*, *елы баз* (збада), *чаршау* (шторы), *пи(ч)*, *шакыр*, *торба*, *кашык*, *хайван* (скотина), *мөрҗә*, *сөлге* (биткә), *тастымал* (кулга), *фандамент* (фундамент), *стайка*, *күпшек* (подушка), *поддор* (могилада) һ. б. Кайбер диалектизмнарны җентекләп тикшерик.

«*Ызба/зба*» (<рус. «изба») көнбатыш диалектка хас; урта диалектның турбаслы, тархан, түбән кама керәшеннәре, пермь; көнчыгыш диалектның калмак, төмән сөйләшләрендә дә күзәтелә [4: 795]. Бурятия татарлары сөйләшендә дә актив. Мәсәлән, *җаб әле пичне, мерҗәсен // кенәген бик салкын былды збада.*

Татар әдәби телендәге *мендәр* сүзе белән беррәттән Бурятия татарларында шул ук мәгънәдә *күпшек* варианты кулланыла. Идел-Урал буе ареалында таралган сөйләшләрдә, мәсәлән, тау ягы, казан арты сөйләшләре төркемнәрендә, минзәлә, камышлы, каргалы, богырыслан, шарлык сөйләшләрендә «мендәр» мәгънәсендә – *күпчек*, чистай, мәләкәс сөйләшләрендә *кепчек* варианты кулланыла. Мәсәлән, *олорак кешеләр күпчек ди мендәрне.* – лш.; *Бу бәләкәй күпчекне салыйк әле.* – мам.; *Ана, ал бу күпчекне, йатып тор диб әйтмәде.* – минз.; *Пар кепчек бирдем.* – мәл.; *Мени бысын башыңа бекла, анары кепчек куйарсын.* – чст. Түбән Кама керәшеннәре сөйләшендә *күпчек* лексемасы «мамыктан гына ясалган мендәр» мәгънәсендә йөри: *күпчек кас мамыгыннан гына була, аны бик кәдерле кунакка гына саласың.* Чагыштырыгыз: тара сөйләшендә *күбешкәк* сүзе 1) «йомшак, көпшәк»; 2) «кабарынкы, йомшак түшәк, мендәр» мәгънәсендә [4: 342].

«*Ыстайка*» сүзе [рус. стойка] түбәндәге мәгънәләрдә кулланыла: 1) каралтылар; 2) каралтыда терлекләр ябу өчен бүрәнәдән мүкләп эшләнгән җылы урын. Мәсәлән, *малларны ыстайкада тота ийәк.* Шундый ук мәгънәләрдә бирелгән сүз том диалектының яүштә-чат сөйләшендә дә бар [4: 801]. Биредә татар теленең көнчыгыш диалекты сөйләшләре белән бәйләнеш күзәтелә.

Ризык атамалары: *бүткән* (түгәрәк камыр җәймәсенә нинди дә булса эчлек салып әзерләнгән ризык), *күмәч* (төче камырдан, майсыз табада пешерелгән җәймә), *кимак* (әче камырдан табага җәеп пешерелә торган, беленнән калынрак камыр азыгы), *көлчә*, *әче су* (эремчек суы), *кабартма*, *кымак*, *аг ип`и*, *эпи*, *күзикмәк*, *буккән* һ. б.

Бу сөйләшләрдә «икмәк» мәгънәсе *әпи/эпи* лексемалары белән белдерелә. Бөре, минзәлә сөйләшләрендә дә шулай: *Эпи кисеп бир әле.* Тау ягы сөйләшләре төркеме, минзәлә, турбаслы, чүпрәле сөйләшләрендә *әпи* варианты таралган. *Ипи [ипӗй], әпи, ипекәй* «хлеб» – бу вариантлар һәммәсе дә (барлык татар диалектларында очрый торган) *әпәй* вариантыннан килә, бу вариант исә бор. **эппэ,* **эбэ* «ипи, көлчә, коймак» сүзенең иркәләү формасы, к. иске тат. *әпетмәк, ипетмәк* (Троянский I: 7) «бәбине ашату», чыгт. *ібі-* «ашау» (Радлов I: 1569), хак. *ипек, інек* < бор. төрки (ДТС: 62) *ebäk* «ипи, икмәк» («балалар телендә», ди М. Кашгари) [7: 307].

Татар әдәби телендә дә, күпчелек татар сөйләшләрендә дә күмәч лексемасы «май, йомырка, шикәр һ. б. ш. ларны кушып әзерләнгән камырдан пешерелә торган ашамлык» дигән мәгънәдә кулланыла. *Күмәч* (*күмәц*) (к. Хайрутдинова 1993: 17–19; ЗДС: 352–353) *кумич, күмәгәч* «булочка, колобок, (белый) хлебец», «пресная лепешка», «ритуальная и обрядовая лепешка» (с разнообразными значениями, к. Хайрутдинова op.cit., Будагов II: 162–163) > чув. диал. *күммеч*, мар. (Исанбаев 1978: 36) *комеч, кӧмеч, кӧмӓч*, удм. (Насибуллин: 121) *кӧмеч* «күмәч; ак (киң мәгъ.) < гом. кыпч., чыгт., уйг. һ. б. (к. Радлов II: 1320) *кӧмеч* (> нуг., каз., к.-калп. *кӧмеш*), башк. *күмәҫ,* кырг. *кӧмӧч* < бор. төрки (ДТС: 314) *кӧмӓč* «көлдә пешерелгән тәбикмәк; күмәч» (әлбәттә, бу сүзнең камырдан пешерелгән ашамлыкларның исәпсез күп төрләрен белдерүе табигый, башк. сөйләшләрендә хәтта шакмак салманы да *күмәс* диләр, к. БТДҺ: 163). Бу сүзне элек-электән (М. Кашгаридан башлап) *күм-ү* («кайнар көлгә күмеп пешерү») сүзеннән дип аңлаталар, ягъни асылда *күммәч* < *кӧм-мӓч* (*-мач*//*-мәч* – ашамлык атамаларын ясагыч кушымча). *Күмәч* < *күммә аш* дип аңлату фонетик закончалыкларга каршы килә [7: 493].

Бурятия татарлары сөйләшләрендә *күмәч* лексемасы «төче камырдан, майсыз табада пешерелгән җәймә» мәгънәсенә ия: *Нәнә көлчә, кабартма пешерәийе.* Мамадыш, лаеш, казан арты керәшеннәре сөйләше, минзәлә, богырыслан, нагайбәк керәшеннәре сөйләше, тобол сөйләшләрендә *көлчә* лексемасы «ачыга изгән арыш яки бодай камырыннан кул белән юкарак итеп җәеп, ут каршында табада пешереп алган ризык» мәгънәсендә кулланыла: *Әни ипи салганда көлчә пешерәдер ийе.* – мам. Минзәлә, бөре, түбән кама керәшеннәре сөйләше, казан арты керәшеннәре сөйләшләрендә әлеге термин «бодай кабартмасы» дигәнне аңлата: *Нәстә кирәк сиңа, менә көлчә.* – т. кам.-крш. Түмән сөйләшендә исә «бодай икмәге» дигән мәгънәдә таралган.

Аерым игътибарны семантик диалектизмнарга – әдәби телдәге шундый ук сүздән мәгънәсе белән аерылып торган берәмлекләргә юнәлтергә кирәк. Бурятия татарларында түбәндәге лексемалар күзәтелә: *чыпчык* «кош» мәгънәсендә (татар әдәби телендә *чыпчык* – чыпчыккошлар семьялыгыннан көрән-соры төстәге кечкенә кош, ягъни «воробей»; *канат* «каурый» мәгънәсендә (татар әдәби телендә *канат* – кошларда, бөҗәкләрдә һ. б. парлы очу органы, ягъни «перо»); *кара җиләк* «карлыган» мәгънәсендә (татар әдәби телендә *кара җиләк* – арчанчалар семьялыгыннан читләре вак тешле эллипссыман яфраклы, яшькелт ал төстәге шарсыман кувшин чәчәкле, күгелҗем кунык белән капланган күксел кара җиләкле вак куакчык, ягъни «черника»), *түбә* «түшәм» мәгънәсендә кулланыла (татар әдәби телендә *түбә* – бинаны, корылманы өске яктан ябып, аны кар-яңгырдан саклый торган каплама, ягъни «потолок»); *шокыр* (*чокыр)* «чынаяк» мәгънәсендә таралган (татар әдәби телендә *чокыр* – җирдә казып ясалган урын, ягъни «яма»); *кызыл карлыган* лексемасы «нарат җиләге» мәгънәсендә таралган (татар әдәби телендә *кызыл карлыган* –

крыжовникчалар семьялыгыннан ашарга яраклы җиләге кызыл була торган куак, ягъни «красная смородина») һ. б.

Өйрәнелгән сөйләшләрдә шулай ук үзенчәлекле алынма диалектизмнар күзәтелә. Алынма диалектизмнар – җирле сөйләштә генә кулланыла торган, әдәби телдә бөтенләй булмаган алынма сүзләр. Мәсәлән, *Мәскәв* – Москва, *заро/уд* – чүмәләнең төре (рус. зарод), *лән* – җитен (рус. лён), *ыстанца* – станция, *стайка* – каралтылар (рус. стойка) һ. б.

Әдәби телдә булмаган, бары сөйләшләрдә генә күзәтелә торган сүзләр лексик диалектизмнар дип атала. Бурятия татарларында шундыйлардан, мәсәлән, *буткән* – түгәрәк камыр җәймәсенә нинди дә булса эчлек салып әзерләнгән ризык, *агач кабыгы* – агач кайрысы, *кенәген* – кичә, *әче су* – эремчек суы, *төш* (зба төше) – өй алды, келәп – гөлҗимеш һ. б.

Өйрәнелгән сөйләшләрдә аерым фонетик, лексик һәм грамматик үзенчәлекләр системасы формалашкан. Тарихи чыганакларга караганда, бу сөйләшләр вәкилләренең күпчелеге Казан һәм Уфа губерналарыннан, ягъни, нигездә, урта диалекттан чыккан. Шул ук вакытта Пенза өязеннән күчеп килгән көнбатыш сөйләшләре вәкилләре дә теркәлә.

Шул рәвешле, Бурятия татарлары сөйләшләре өчен түбәндәге сөйләшләр беренчел булып тора: казан арты сөйләшләре төркеме, шулай ук Идел буе һәм Урал төбәкләрендә таралган урта һәм көнбатыш диалект сөйләшләре. Аларга хас үзенчәлекләргә югарыда каралган күренешләрдән тыш, мәсәлән, [к]~[к], [г]~[ғ], [й]~[ж] кебек параллель кулланылышларны кертергә мөмкин.

Күзәтүләр күрсәткәнчә, Бурятия татарлары сөйләшләре тарихи диалекталь базалары һәм чит телле контактлар нәтиҗәсендә формалашкан лингвистик үзенчәлекләрнең үзара бәйләнешен чагылдыра.

Татар диалектларының гомуми үзенчәлекләрен саклап калу белән беррәттән, рус теле һәм башка төрки телләрнең йогынтысы сизелә. Бу йогынты көнкүреш лексикасында, географик атамаларда һәм кайбер грамматик конструкцияләрдә аеруча көчле. Аерым аваз үзгәрешләре, яңа сүзләр керү һәм кайбер сүзләрнең мәгънәләре киңәю яки тараю – болар барысы да тел яшәеше һәм үзгәрешләрнең дәлиле булып тора.

Шулай итеп, Бурятия татарларының тел үзенчәлекләрен өйрәнү, телнең региональ аспектларын ачыклау гына түгел, ә шулай ук татар халкының тарихи-мәдәни багланышларын, миграция юлларын һәм ассимиляция процессын аңлау өчен дә мөһим.

## Әдәбият

1. *Баранникова Л. И* . Говоры территорий позднего заселения и проблема их классификации // Вопросы языкознания. 1975. № 2. С. 22–31.

2. *Баталова С. Р.* Региональная национально-культурная автономия татар Бурятии: история, становление, перспективы развития. Улан-Удэ: Изд-во Бурят. гос. ун-та, 2012.

3. *Кондратьева В. В., Батуева И. Б.* Численность и расселение татар на территории Бурятии // Вестник ЧГАКИ. 2013. №3 (35). URL: https://cyberleninka.ru/article/n/chislennost-i-rasselenie-tatar-na-territorii-buryatii (дата обращения: 28.10.2025).

4. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

5. Татар халык сөйләшләре: Ике китапта / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х.Хәйретдинова һ. б. Казан: Мәгариф, 2008. Беренче китап. 463 б.

6. Татар халык сөйләшләре: Ике китапта / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ. б. Казан: Мәгариф, 2008. Икенче китап. 463 б.

7. Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда / төз. Р.Г. Әхмәтьянов; фәнни мөх-р Р.Т. Сәфәров. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. Т. II. 567 б.

***Хөсәинова Алинә Җәмил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Хусаинова Алина Ямилевна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела ареальной лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*husainova_alina@mail.ru*